| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

09.07.2021 — № 659

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» Нурлат муниципаль районы Советының 2021 елның 05 февралендәге 41 номерлы карары нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының административ комиссиясен (алга таба Административ комиссия) төзергә.

2. Расларга:

Нурлат административ комиссиясе составы (1 нче кушымта);

Административ комиссия эш регламенты (2 нче кушымта).

3. Бер составтагы административ комиссиянең вәкаләтләр чоры 5 ел тәшкил итә, ул аның беренче утырышы уздырылган көннән исәпләнә һәм яңа составтагы Административ комиссиянең беренче утырышы уздырылган көнгә кадәр дәвам итә.

4. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Нурлат муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2006 елның 08 февралендәге 3 номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү хакында» Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2006 елның 21 апрелендәге 334 номерлы карары;

- Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Нурлат муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2006 елның 08 февралендәге 3 номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү хакында» Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2006 елның 21 апрелендәге 334 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2007 елның 16 гыйнварындагы 28 номерлы карары;

- Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2006 елның 08 февралендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 07 маендагы 425 номерлы карары;

- Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Нурлат муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2006 елның 08 февралендәге 3 номерлы күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү хакында» Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2007 елның 16 гыйнварындагы 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2007 елның 26 июлендәге 755 номерлы карары;

- Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2006 елның 08 февралендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 20 гыйнварындагы 36 номерлы карары;

- Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының 2006 елның 08 февралендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 16 декабрендәге 1099 номерлы карары;

- Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты комиссияләре составына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 13 декабрендәге 1073 номерлы карарының 11 пункты.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р.Хәмзин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 09.07.2021 ел, 659 номерлы карарына 1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының административ комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе | Хәмзин Рәфис Рафик улы - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Комиссия рәисе урынбасары | Морадыймов Руслан Хәлил улы - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Комиссия секретаре | Залиашвили Татьяна Анатольевна - административ комиссиянең җаваплы сәркатибе |
| Комиссия әгъзалары | Терентьев Федор Юрьевич - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре идарәчесе |
| | Титарева Олеся Александровна-Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |
| | Гәрәев Марсель Мансур улы - Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы |
| | Сәмәрханова Сирин Наил кызы - «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газетасы корреспонденты (килешү буенча) |

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 09.07.2021 ел, 659 номерлы карарына 2 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АДМИНИСТРАТИВ КОМИССИЯСЕНЕҢ ЭШ РЕГЛАМЕНТЫ

Әлеге Регламент Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы административ комиссиясенең (алга таба-административ комиссия) эш тәртибен билгели.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ комиссия Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән төзелә.

1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, "Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларны оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) һәм Нурлат муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Административ комиссия Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында кодексында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау өчен төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы чикләрендә гамәлдә була.

1.4. Административ комиссия бурычлары административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә һәр эшне һәрьяклап, тулы, объектив һәм вакытында карау, чыгарылган карарны үтәүне тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү.

1.5. Бер составтагы административ комиссиянең вәкаләтләр чоры 5 ел тәшкил итә, ул аның беренче утырышы уздырылган көннән исәпләнә һәм яңа составтагы Административ комиссиянең беренче утырышы уздырылган көнгә кадәр дәвам итә. Күрсәтелгән срок узганнан соң, Административ комиссия яңа составтагы административ комиссиянең беренче утырышы көненә кадәр үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны дәвам итә.

1.6. Административ комиссия әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла.

1.7. Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты административ комиссиянең үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан әгъзасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча административ комиссия әгъзасы урынына административ комиссиянең яңа әгъзасын билгеләп куярга тиеш.

1.8. Административ комиссиянең тулы исеме язылган мөһере бар.

## 2. Административ комиссия эшен оештыру

2.1. Административ комиссия рәис урынбасарыннан, рәис урынбасарыннан, җаваплы секретарьдан һәм 4 (дүрт) әгъзадан (алга таба - административ комиссия әгъзалары) тора, алар Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

2.2. Административ комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашыралар.

2.3. Административ комиссиянең персональ һәм санлы составы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан кимендә 7 кеше күләмендә билгеләнә һәм төгәл сан тәшкил итәргә тиеш.

2.4. Административ комиссия составына даими штат нигезендә административ комиссиянең җаваплы секретаре керә. Административ комиссиянең башка әгъзалары, шушы Регламентның 2.5 пунктында каралган очраклардан тыш, иҗтимагый башлангычларда эшлиләр.

2.5. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының карары буенча Административ комиссиянең башка әгъзалары үз вазыйфаларын даими түләүле нигездә җирле бюджет акчалары исәбеннән башкара алалар.

2.6. Административ комиссия рәисе рәис урынбасарлары һәм комиссиянең җаваплы секретаре арасындагы вазыйфаларны бүлә, аларның функцияләрен Татарстан Республикасы Законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә билгели.

2.7. Административ комиссия рәисе комиссия әгъзаларының, шулай ук комиссия рәисе урынбасарының һәм җаваплы секретареның квалификациясен күтәрү эшен оештыра.

2.8. Административ комиссия килүчеләрне кабул итә ала. Килүчеләрне кабул итү тәртибе административ комиссия рәисе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

2.9. Административ комиссия адресына килгән шикаятьләр һәм гражданнар һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләре гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.

## 3. Административ комиссия утырышын чакыру һәм уздыру тәртибе

3.1. Административ хокук бозулар турында эшләрне карау Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә административ комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.2. Административ хокук бозулар турындагы эшләр административ комиссия тарафыннан утырышларда карала. Административ комиссия утырышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турындагы карар аның рәисе тарафыннан кабул ителә, ә рәис урынбасары булмаганда, административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар кергән саен, аена кимендә 1 тапкыр кабул ителә.

3.3. Административ комиссия утырышлары административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау срокларын үтәүне тәэмин итә торган вакыт аралыгы белән уздырыла.

3.4. Административ комиссиянең җаваплы секретаре утырыш үткәрелүгә кимендә 3 көн кала административ комиссия әгъзаларына утырышны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә.

3.5. Административ комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм әгъзалары бу хакта административ комиссиянең җаваплы секретарена, кагыйдә буларак, Административ комиссия утырышы көненә кадәр 1 эш көне кала хәбәр итәргә тиеш.

3.6. Административ комиссия утырышы, әгәр анда административ комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы була.

3.7. Карар, административ хокук бозу турындагы эш буенча билгеләмә утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

## 4. Административ җәза бирү турындагы карарны үтәү

4.1. Административ комиссия чыгарган карарлар Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә башкарыла.

4.2. Административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарларның, билгеләмәләрнең һәм тәкъдимнәрнең эш буенча производствода катнашучы затларның, башка физик һәм юридик затларның башкарылуын тикшереп торуны административ комиссиянең җаваплы секретаре гамәлгә ашыра.

## 5. Административ хокук бозуларны профилактикалау

5.1. Административ хокук бозуларны кисәтү максатларында Административ комиссия үз эшчәнлеген федераль суд приставлары хезмәте идарәсенең территориаль бүлекләре, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән координацияли.

5.2. Административ комиссия күчмә утырышлар үткәрә, шул исәптән муниципаль район җирлекләрендә, председатель раслаган график нигезендә.

5.3. Административ комиссия үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре уздыру юлы белән профилактик эш оештыра.